**Низамиевларның укытучылар династиясе.**



**Низамиев Нәбиулла Низаметдин улы.**

1919-1920 нчы елларда Түбән Кенә, Хәсәншаих авылларында укытучы булып эшли башлый.

1921 нче елда Түбән Кенә башлангыч мәктәбенә укытучы итеп билгеләнә.

1924 нче елда Хәсәншаих башлангыч мәктәбенә директор итеп күчерелә.

1932-1937 нче елларда Түбән Кенә башлангыч мәктәбенәдә директор булып эшли.

1940-1942 нче елларда Түбән Кенэ җидееллык мәктәбендә завуч булып эшли.

1942-1952 нче елларда директор вазифасын башкара.

Педагогик стажы - 33 ел.



**Низамиева Венера Нәбиулла кызы.**

1946-1957 нче елларда Түбән Кенә, Кенәбаш, Карадуган мәктәпләрендә башлангыч сыйныф укытучысы булып эшли.

1957-1983 нче елларда Пермь өлкәсе Горнозаводский районы Пашия посёлогында башлангыч сыйныфларда укыта.

Педагогик стажы – 37 ел.



**Морзаева (Низамиева) Мәрфуга Нәбиулла кызы.**

1963-1967 нче елларда  Яшел Үзән районы  Зур Кавал сигезъеллык мәктәбендә башлангыч сыйныф укытучысы булып эшли.

1967-1994 нче елларда Таджикстан республикасы Нурек шәһәрендә башлангыч сыйныфларда укыта.

1994-2015 нчы елларда Кенә мәктәбендә башлангыч сыйныфларда укытучы булып эшли.

2015-2019 нчы елларда 5-9 нчы сыйныфларда сыйныф җитәкчесе вазифасын башкара.

Педагогик стажы – 56 ел.



**Морзаева Лилия Вәсигать кызы.**
(Морзаева Мәрфуганын кызы)

1990-1999 нчы елларда Казан шәһәре Киров районының 50 нче номерлы гимназиясендә рус теле һәм әдәбияте укытучысы булып эшли.

Педагогик стажы – 9 ел.




**Низамиева Сәгыйрә Нигъмәтҗан кызы.**
(Низамиев Нәбиулла килене)

1946-1950 нче елларда Балтач районы Субаш мәктәбендә башлангыч сыйныфлар укыта. Шул ук вакытта югары сыйныфларда татар теле һәм әдәбияте дәресләрен дә алып бара.

1950-1953 нче елларда Арча районы Хәсәншаих мәктәбендә укытучы булып эшли.

1953-1954 нче елларда Кенә урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияте дәресләре укыта.

1954- 1962 нче елларда Кенә урта мәктәбендә завуч вазифасын башкара.

1962-1984 нче елларда шул ук мәктәптә татар теле һәм әдәбияте укытучысы булып эшли.

1986-1992 нче елларда Карадуган, Кенә урта мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияте дәресләрен укыта.

Педагогик стажы - 44 ел.



**Фролова (Низамиева) Ризидә Вәкил кызы.**

1978-2015 нче елларда Балтач районы Субаш мәктәбендә башлангыч сыйныф укытучысы булып эшли.

Педагогик стажы - 37 ел.



**Низамиев Шамил Вәкил улы.**

1991-2014 нче елларда Бакый Рәхимов исемендәге Кенә төп мәктәбендә физика укытучысы булып эшли.

2014 нче елдан Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге башлыгы.

Педагогик стажы – 23 ел



**Низамиева Римма Наил кызы.**

(Низамиева Сәгыйрә килене)

1991-2018 нче елларда Бакый Рәхимов исемендәге Кенә төп мәктәбендә математика һәм информатика укытучысы булып эшли.

2018 нче елдан Таузар башлангыч мәктәп - балалар бакчасы диреторы.

Педагогик стажы -32 ел.



**Низамиев Рамил Вәкил улы.**

1994-1998 нче елларда Кенә урта мәктәбендә география укытучысы булып эшли.

1998-2004 нче елларда шул ук мәктәптә тәрбия эшләре буенча директор урынбасары вазифасын башкара.

2004 нче елдан Бакый Рәхимов исемендәге Кенә төп мәктәбе директоры.

Педагогик стажы - 29 ел.



**Низамиева Гөлнара Гыйлфан кызы.**

(Низамиева Сәгыйрә килене)

1994-1998 нче елларда 1нче номерлы “Ак чәчәк” балалар бакчасында тәрбияче булып эшли.

1998-2008 нче елларда Кенә урта мәктәбендә озайтылган көн группасы тәрбиячесе.

2008нче елдан шул ук мәктәптә башлангыч сыйныфларны укыта.

Педагогик стажы - 29 ел.



**Низамиева Әлфия Равил кызы.**

(Низамиева Сәгыйрә килене)

1988-1993 нче елларда Казан шәһәре 69 нчы мәктәптә музыка укытучысы булып эшли.

1993-2021нче елларда 1нче номерлы “Ак чәчәк” балалар бакчасында музыка җитәкчесе.

Педагогик стажы -33 ел.